**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Андреевка авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«24» октябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге Андреевка авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлегенең Андреевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.

Халык җыенында рәислек итүче Н.И. Егорова

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Н.И. Егорова